ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«10» 12 2025 г.

**КАРАР**

№ 300

**Мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу һәм хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү буенча комиссия турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль закон, Балтач районы прокуратурасының 2024 елның 14 мартындагы 02-08-01-2024/Прдп 87-24-20920011 номерлы протесты нигезендә Балтач муниципаль район Башлыгы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль район Башлыгының 2018 елның 23 июнендәге 103 номерлы карары (№148, 27.05.2024 елгы редакциядә) белән расланган мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу һәм хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү буенча комиссия турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.3 пунктындагы «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

а) муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның коррупциягә каршы тору максатларында «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне, бурычларны үтәвен тәэмин итүдә (алга таба - хезмәт тәртибенә таләпләр һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләр));

1.2. Нигезләмәнең 3.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле «е» пунктчасы өстәргә:

«е) коррупциягә каршы көрәш максатларында федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне һәм бурычларны үтәүгә комачаулый торган аңа бәйле булмаган хәлләр барлыкка килүе турында муниципаль хезмәткәргә хәбәр итү.»;

1.3. Нигезләмәнең 3.2.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.4) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б», «е» пунктчаларының бишенче абзацында күрсәтелгән хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмә әзерләнә.».

1.4. Нигезләмәнең 3.2.5 пунктчасында «3.1 пунктының «д» пунктчасында сүзтезмәсен» «3.1 пунктының «д» һәм «е» пунктчаларында» сүзтезмәсенә алмаштырырга;

1.5. Нигезләмәнең 3.2.6 пунктындагы «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) әлеге Нигезләмәнең 3.1 нче пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д», «е» пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яисә хәбәрнамәләрдә бәян ителгән мәгълүматны.;»;

1.6. Нигезләмәнең 3.2.6 пунктындагы «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б» пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында һәм «д», «е» пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм хәбәрнамәләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән нәтиҗә, шулай ук әлеге Нигезләмәнең 3.9, 3.10.3, 3.11 пунктлары яисә башка карар нигезендә карарларның берсен кабул итү өчен тәкъдимнәр.»;

1.7. Нигезләмәнең 3.3.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.2. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «д», «е» пунктчаларында күрсәтелгән хәбәрнамә, кагыйдә буларак, комиссиянең чираттагы (планлы) утырышында карала.».

1.8. Нигезләмәнең 3.4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү турындагы мәсьәлә карала торган муниципаль хезмәткәр яисә җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән граждан катнашында уздырыла. Комиссия утырышында шәхсән катнашу нияте турында муниципаль хезмәткәр (яки граждан) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б», «и» пунктчалары нигезендә тапшырыла торган мөрәҗәгатьтә, гаризада яисә хәбәрнамәдә күрсәтә.».

1.9. Нигезләмәнең 3.4.1 пунктындагы «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) әгәр әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «б», «е» пунктчаларында каралган мөрәҗәгатьтә, гаризада яисә хәбәрнамәдә муниципаль хезмәткәрнең яисә гражданның комиссия утырышында шәхсән катнашырга нияте турында күрсәтмә булмаса;»;

1.20. Нигезләмәгә түбәндәге эчтәлекле 10.3.4 пунктчасы өстәргә:

«10.3.4. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «е» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган хәлләр килеп чыгу һәм аның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мөмкин түгеллеге арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булуын танырга;

б) дәүләт хезмәткәренә бәйле булмаган хәлләр килеп чыгу һәм аның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яисә) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәү мөмкин түгеллеге арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булмавын танырга.»;

1.21. Нигезләмәнең 3.11 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.11. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы «а», «б», «г», «д», «е» пунктчаларында күрсәтелгән мәсьәләләрне карау йомгаклары буенча, моңа нигезләр булганда, комиссия әлеге Нигезләмәнең 3.7 - 3.10, 3.10.1-3.10.3 һәм 3.11.1 пунктларында каралган башка карар кабул итә ала. Мондый карар кабул итү нигезләре һәм мотивлары комиссия утырышы беркетмәсендә чагылдырылырга тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль район башлыгы урынбасары Н.Н. Сабирҗановка йөкләргә.

Балтач муниципаль
район Башлыгы Р.Р.Нотфуллин